КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08.02.2019 № 2-П

г. Казань

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетына коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү Тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасының 2003 елның 12 маенда кабул ителгән 16-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында»гы законының 21нче маддәсенә яраклы рәвештә боерам:

1. Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетына коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү Тәртибен расларга.

2. Шуны гамәлгә кертергә:

коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрне карау хокук, оештыру һәм кадрлар эше бүлеге тарафыннан башкарыла;

коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләр белән эш итүче вазыфаи затлар хезмәткә кагылышлы һәм конфиденциаль характердагы мәгълүматның сакланып калуы өчен Россия Федерациясе кануннары буенча билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау Комитетының 08.02.2019 2-П №лы боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетына коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү Тәртибе

1. Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетына коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү Тәртибе (алда – Тәртип, Комитет), Татарстан Республикасының 2003 ел 12 маенда кабул ителгән 16-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында»гы законының 21нче пунктын үтәп, Комитетта коррупциягә каршылык күрсәтүнең нәтиҗәлелеген күтәрү максатында эшләнгән. Хәзерге Тәртип коррупция юнәлешендәге, коррупция һәм куркытып акча алу фактлары турында мәгълүматны, гражданнарның законлы мәнфәгатьләрен һәм хокукларын чикләү, хезмәткәрләр тарафыннан эштә үз-үзен тотуга таләпләрне бозу, шулай ук Комитетта Татарстан Республикасының дәүләт хезмәткәрләре (алда – хезмәткәрләр) һәм дәүләт хезмәте булмаган һәм Комитетның эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү вазифаларын башкаручылар тарафыннан хезмәт урыныннан законсыз файдалану билгесе булган башка эшләрне үз эченә алган фактлар буенча гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрне (алда – мөрәҗәгать) карау үзенчәлекләрен гамәлгә кертә. Башка затларга кагылышлы шундый фактларны үз эченә алган мөрәҗәгатьләр, 2006 елның 2 маенда кабул ителгән 59-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында»гы Федераль законның 8нче маддәсе 3нче өлешенә яраклы рәвештә, тиешле органга яки мөрәҗәгатьтә күтәрелгән сораулар буенча карар кабул итәргә хаклы булган вазыфаи затка юлланырга тиеш.

2. Мөрәҗәгать «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында»гы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлә һәм карала.

Мөрәҗәгатьтә әзерләнүче, башкарылучы яки башкарылган хокук бозу, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яки башкарган зат турында мәгълүмат булганда, бу мөрәҗәгать, күтәрелгән сорау буенча карар кабул итәргә хаклы булган хокук саклау органына җибәрелә.

3. Хокукый, кадрлар һәм оештыру эшләре бүлеге тарафыннан хезмәткәргә карата хезмәт тикшерүе башкарыла (хезмәткәрдән язма аңлатма таләп ителәчәк).

4. Мөрәҗәгатьтә чагылган ришвәтчелек турында фактлар хезмәт тикшерүен башкарган комиссия нәтиҗәсенә нигезләнеп расланган очракта Комитет рәисе (аның вазифаларын башкаручы зат) Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының Татарстан Республикасының дәүләҗ гражданлык хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр низагларын җайга салу комиссиясенә гариза тапшыра. Күрсәтелгән фактлар

расланган очракта, хезмәткәргә карата, аның язма аңлатмасы анализыннан чыгып, Россия Федерациясенең норматив хокук актлары белән каралган җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул ителә.

Хезмәт тикшерүе нәтиҗәсендә әзерләнә, башкарыла торган яисә башкарылган законсыз эш һәм шулай ук аны әзерли, башкара торган яки башкарган зат турында билгеле булган очракта, тиешле мәгълүмат хокук саклаут органнарына җибәрелергә тиеш.

5. Мөрәҗәгать җибәргән гражданинга җавапны, тикшерү вакытында структур бүлек башлыкларыннан кергән язма тәкъдимнәрне исәпкә алып, җаваплы зат әзерли.

Җавап мөрәҗәгатьне карау барышында алынган структур бүлекчәләр җитәкчеләренең язма тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнә.

6. Әгәр дә мөрәҗәгатьтә җаваплы кешегә карата ришвәтьчелек фактлары турында мәгълүматлар булса, соңгысы мөрәҗәгатьне тикшерүдә катнашмый. Андый мөрәҗәгатьне карау хокукый, кадрлар һәм оештыру эшләре бүлеге җитәкчесе тарафыннан башкарыла.